# Гостиная татарского языка

## Уважаемые мамы и папы, бабушки и дедушки!

Новые подходы в обучении детей татарскому и русскому языкам с использованием учебно-методических комплектов освещены по адресу
**http://mon.tatarstan.ru/rus/umk_doshkolniki.htm**
Здесь Вы найдете много интересного и разнообразного материала для занятий с детьми

На телевизионном канале ТРК «Новый век» для наших детей показываются серии передач на татарском языке :

**"В стране сказок" («Әкият илендә»)** по воскресениям в 9 часов 30 минут, по будням - передача **"Гостинчик для малышей" (Күчтәнәч")** днем в 15 часов 15 минут и вечером в 21час.00 минут.

Уважаемые родители, татарские слова в этих передачах знакомы нашим детям, вы можете поинтересоваться, побеседовать с детьми о том, что им было интересно, о чем говорилось.

**Всегда можно просмотреть эти программы по следующему адресу**
**http://mon.tatarstan.ru/rus/ekiyat_ilende.htm**

Мультфильмы на татарском языке производства студий «Татармультфильм» и «Союзмультфильм» (в переводе) размещены на сайте
**http://mon.tatarstan.ru/rus/info.php?id=539365**

## Хөрмәтле әти-әниләр, бабайлар һәм әбиләр!

Татарстан "Яңа гасыр" телеканалында балалар өчен тапшырулар күрсәтелә:

Якшәмбе көннәрендә 9 сәгать 30 минутта **"Әкият илендә"** тапшыруын карый аласыз, эш көннәрендә 15.15 һәм 21.00 сәгатьләрдә **"Күчтәнеәч"** тапшыруын тәкъдим итәләр.

Тапшыруларны балалар белән бергәләп карарга чакырабыз.

Сезнең фикерләрегез белән уракташуыгызны, тәкъдимнәрегезне үзебезнең балалар бакчасы сайты битләрендә көтеп калабыз.

# “САЛАВАТ КҮПЕРЕ”

**«Салават күпере» сайты** аша балачак дөньясына кереп чумдың! Бу дөнья – иң матур, тылсымлы, күңелле, рәхәт җир (һәм иң сөендергәне − монда сиңа ничә яшь булуы бер дә мөһим түгел).

«Салават күпере» − **мәктәпкәчә һәм башлангыч мәктәп яшендәге** (3−12 яшь) **балалар өчен** бердәнбер **татар әдәби-нәфис журнал.** Аның тарихы 20 еллык вакытны үз эченә сыйдырган.

Белгәнеңчә, салават күпере − табигатьнең иң матур күренешләреннән берсе. Шуңа журналның исемендә балачакның иң матур уй-фикерләре, теләк-хыяллары салават күпере төсләрендә чагыла. «Салават күпере» − гамьсез бала чагыбыз символы, сабыйларның иң зур шатлыгы!

Дускай, әйдә, сайт буенча сәяхәт итеп, балачакның рәхәтен тоеп карыйк әле. Күргәнеңчә, монда өч зур ил бар – СалКүперстан, ЗурСити, НәниЛэнд. Алар бик төрле һәм кызыклы. Мәсәлән, СалКүперстанга кереп чыксаң, син журналда басылган **кызыклы әкият-хикәятләр, шигырьләр, уеннарны** зур-зур абый-апалар иҗат итүен белерсең. Кемнәр икән алар? Ә матур-матур рәсемнәрне кем ясый?

«Салават күпере»ндә сиңа яхшы таныш геройлар – Шүркә, Елмай, Йомшаккай, Матуркай һәм Шалай дус-тату яшәп яталар. Син алар белән дә бик тиз уртак тел табарсың.

ЗурСити иленә юл алганда үзең белән әти-әниең, укытучыларың һәм тәрбиячеләреңне дә чакыр. Анда алар өчен **файдалы мәгълүмат** бик күп.

Ә НәниЛэнд – гади ил генә түгел, ә җир йөзендәге һәр баланың иң татлы хыялы... Ышансаң − ышан, ышанмасаң − ышанма, ләкин нәкъ менә бу илдә син бөтен сорауларыңа җавап табарсың! Монда яратып укыган **язучы һәм шагыйрьләрнең әсәрләре** (Зиннур абый Хөснияр, Ләбиб абый Лерон, Рөстәм абый Мингалим, Равил абый Фәйзуллин, Роберт абый Миңнуллин һ.б.); **төрле халыкларның әкитләре**; **әйләнә-тирә дөнья хәлләре** һәм **күренекле шәхесләрнең тормышлары** тупланган. Бу илдә иң мавыктыргыч дәресләргә дә кереп чыгарсың − **уку, язу, матур сөйләм, кызыклы арифметика, рәсем сәнгате, тәрбия һәм этика кагыйдәләре, кул эшләре, тормыш иминлеге нигезләре, татар, рус һәм инглиз телләрен өйрәнү...** Ә тагын... тагын! Оригиналь **кроссвордлар, сканвордлар, башваткычлар, ребуслар, буяугычлар, табышмаклар**! Рәхәтләнеп күңел ач!

Дускай,син үзең дә журнал әзерләүдә катнаша аласың. Ничек дисеңме? Бик гади − **«Нәкыш», «Былбыл», «Мин бит бу!»** кебек **бәйгеләргә** рәсемнәреңне, хикәя-шигырьләреңне, фотоларыңны җибәрсәң, аларны, һичшиксез ,«Салават күпере» битләрендә күрерсең.

Балачак дөньясы сине көтә! Рәхим ит!

## Салават купере (Радуга)

«Салават күпере» («Радуга») – это лучший журнал для детей дошкольного и младшего школьного возраста. Единственный журнал для детей на татарском языке (в качестве основного). Малыши не только совершенствуют свои знания татарского, но и получают возможность познать основы русского и английского языков. Авторами «Салават күпере» являются заслуженные деятели культуры и искусств, лауреаты различных премий и конкурсов РТ и РФ, видные детские писатели и поэты.

Журнал «Салават күпере» существует уже более 20 лет (дата создания март 1990 года). Сегодня журнал «Салават күпере» остается единственным в Республике Татарстан периодическим изданием на татарском языке, специализирующимся непосредственно на детях. Название же журнала стало в определенной степени символом счастливого и беззаботного детства.

**Содержание:**

1. Произведения видных детских татарских писателей, поэтов (З.Хуснияр, Л.Лерон, Р.Мингалим, Р.Файзуллин, В.Нуриев, Р.Миннуллин и др.); сказки народов России и мира; описания событий окружающей действительности и жизни отдельных людей («Тәрбия дәресе» («Урок нравственности»), «Сәяхәтче әкият» («Сказка-путешественница»), «Хыялый Хәйрүш» («Мечтатель Хайруш»), «Яшел бишек» ("Зелёная колыбель”) и т.д.).

2. Различного рода задания для ребенка, которые представляются в виде:

а) уроков чтения, письма, развития речи, основ счета, рисования, воспитания и этики, рукоделия, безопасности жизнедеятельности («Әлифба дәресе» («Уроки азбуки»), «Нәкыш» («Рисунок»), «Сак бул!» («Будь осторожен!»), «Алтын куллар» («Золотые руки») и др.), специализированных занятий по изучению английского языка через татарский и русский языки;

б) кроссовордов, скандвордов, головоломок («Башкатыргычлар» («Головоломки»), «Кызыклы саннар» («Интересные цифры»));

в) подвижных игр, сценариев проведения различных мероприятий и праздников («Күңелле тәнәфес» («Весёлая перемена»), «Әниләр көне» («День матери»), «Яңа ел бәйрәме» («Новый год») и др.).

3. Основу ещё одного блока составляет один из видов терапии – сказкотерапия («Әкияттерапия» – «Сказкотерапия»). Его ведут квалифицированные специалисты в области детской психологии, которые в форме сказок описывают отдельные проблемные ситуации и возможные пути их решения, тем самым способствуют созданию гармоничных отношений между детьми и их родителями, между ребенком и его окружением.

4. В рамках этого блока предусматривается осуществление так называемого «личного» общения, «обратной связи» юных читателей и их родителей с коллективом редакции. Каждый ребенок имеет возможность лично поучавствовать в создании журнала, прислав нам свои первые творческие

работы, фотографии и презентации самих себя в форме шутливых четверостиший.

Кроме того, на страницах «Салават күпере» регулярно происходит знакомство читателей с юными талантами, дарованиями республики, достигших значительных успехов в творчестве, искусстве, спорте и т.д. Публикуя их фотографии, краткие презентации и список основных достижений, редакция стремится поощрить достижения одних, чтобы остальное большинство стремилось к самосовершенствованию. Многолетняя работа в данном направлении показала, что это является хорошим способом для стимулирования познавательной, творческой и эмоциональной активности подрастающего поколения.

Кроме основного содержания журнала «Салават күпере», в реализации посталенных цели и задач большое место занимают:

1) Сказочные образы (лесной мальчик Шурка, девочка Елмай, котик Йомшаккай и волшебная птичка Матуркай (персонажи передачи «Күчтәнәч» на телеканале «Новый век»), мальчик Шалай), сопровождающие каждую рубрику издания и используемые редакцией для акцентирования внимания юных читателей и их родителей на основных идеях представленного материала, постановки вопросов и проблемных ситуаций для самостоятельного размышления и принятия решений, осуществления «обратной связи», общения с коллективом редакции, закладывание осознания о том, что «Салават күпере» и все его герои, авторы являются верными друзьями каждого ребенка. При этом применяются следующие методические приемы: «вопрос-ответ», краткие пояснения-вставки или справки-шпаргалки в виде толкования лексического значения возможно новых, непонятных для читателя слов, представления перевода с татарского на русский и английский языки некоторых из них и др. Так, прием «вопрос-ответ» предоставляет возможность родителям, не имеющим педагогического образования, самостоятельно заниматься развитием своих детей.

2) Художественное оформление «Салават күпере», которое по сути своей содействует усилению и художественному подтверждению основных идей, настроения, поставленных проблем и принятых решений в журнале. Каждый представленный материал имеет свое продуманное до мельчайших подробностей оформление, которое к тому же воспитывает у юных читателей эстетический вкус, формирует особенности восприятия описываемых предметов, событий, явлений окружающей действительности. Таким образом, журнал, воздействуя сначала через внешнее оформление, а потом уже через заключенное в нем содержание, способствует успешному знакомству юных читателей с изданием.

**Баланы ”тәмле сүзләргә” өйрәтәбез.**

***Хәерле иртә! Хәерле көн! Хәерле кич! Тыныч йокы! (Ф.Бәдретдин)***

Тәмле әйбер ашагач, авызга рәхәт була. Тәмле сүз ишеткәч, күңелгә рәхәт була. Ашый торгач, тәмле әйбер бетә. Ә тәмле сүз… Күпме генә тыңласаң да, күпме генә кабатласаң да, тәмле сүзнең кадере китми, рәхәте әйткән кешегә дә, ишеткән кешегә дә житә.

Безнең телебездә тәмле сүзләр бихисап! Сез дә беләсез аларны. Төн узып, көн туу белән әйтелә торганы нинди әле? Әйе, шул: «Хәерле иртә!». Шуны бер отып алсагыз, өйдәгеләрне, күршеләрне, дусларны «Хәерле иртә!» дип сәламләргә онытмыйсыз инде! Әле тагын «Хәерле көн!», «Хәерле кич!» дигән сүзләребез бар. Алары да онытыла күрмәсен. Хәер, көн саен, кич саен кабатлап торгач, ничек онытылсын ди алар?!

Хуш, көнне кешеләргә яхшылык, дөньяга иминлек теләп башладык. Ә нинди теләк белән тәмамлыйбыз! Шулай! Тыныч йокы теләп: «Тыныч йокы, әнием!», «Тыныч йокы, әтием!», «Тыныч йокы үземә, тыныч йокы күземә!»

**Хәерле иртә! (Л.Лерон)**

Әтәчтән дә иртәрәк
Уяндым мин, әлбәттә.
- Хәерле иртә, әнкәм!
- Хәерле иртә, әткәм!

Үзем урын җыям мин,
Үзем юына алам.
- Хәерле иртә, әбкәм!
- Хәерле иртә, бабам!

Мәктәпкә үзем барам,
“Бишле”ләр генә алам.
- Хәерле иртә, апа!
- Хәерле иртә,
мәктәп!

**Хәерле иртә! (Х.Халиков)**

Иртән торып чыгуга,
Урап алды чебиләр.
Әй сөйлиләр, сөйлиләр:
- Чи-чи, чи-чи-чи… – диләр.

Казлар әйтә: «Га-га-га»,
Ә үрдәкләр: «Бак-бак-бак».
Нәни бәбкәләре дә:
- Пип-пип, – диләр, такмаклап.

Берсен тотып иркәлим…
Икенчесен иркәлим…
Алар: «Пип-пип-пип», – дисә,
Мин: «Хәерле иртә!» – дим.

Тукта, тукта! Нишләргә?
Әле төште хәтергә:
Әнигә бит шулай дип
Онытканмын әйтергә.

**Тыныч йокы (Ш.Галиев)**

Тыныч йокы әнкәйгә!
Тыныч йокы әткәйгә!
Тыныч йокы абыема!
Тыныч йокы радиога!

Тыныч йокы үземә,
Тыныч йокы күземә!

Тыныч йокы курчакларыма,
Куяннарыма – куркакларыма!

Тыныч йокы сәгать күкесенә дә,
Тыныч йокы бөтенесенә дә!
Юк, юк, күке ятсын,
Иртән безне уятсын!

## Тәрбияле бала җанга – шатлык, йөзгә аклык китерер



Ата-аналарның, тәрбиячеләрнең алдында торган җаваплы, изге бурычларның берсе – балаларны кечкенәдән инсафлы, әдәпле, мәрхәмәтле итеп тәрбияләү. Кеше гомеренең беренче җиде елы бала үсешендә аеруча җаваплы. Нәниләр һәрнәрсәне йотылып, тирән кызыксынып өйрәнәләр һәм әдплелек сыйфатларын да тиз отып үзләштерәләр. Кечкенәләрне үз-үзләрен әдәпле тоту, кешеләр белән аралашу күнекмәләренә өйрәтү бала туган көннән үк башланырга тиеш.

Ә нәрсә соң ул әдәп яисә әдәпле булу? Әдәп ул – җәмгыятьтә үз-үзеңне тота белү кагыйдәләре дигән сүз, ягъни аралашу осталыгы, кешеләргә игътибарлы, инсафлы мөгамәлә, табигатьне ярату һәм аңа сакчыл мөнәсәбәт һ.б. Шуңа күрә, укырга-язарга яисә санарга өйрәтү белән беррәттән, нәниләргә әдәплелек күнекмәләре бирү дә бик мөһим. Бала күпме генә уку-язу күнекмәләренә ия булмасын, әгәр ул әдәплелек кагыйдәләрен үзләштермәсә, аңа тормышта үз урынын табу авыр булачак.

Ә халык авыз иҗаты тәрбия турында нәрсә сөйли? Татар халык мәкальләре:

- Баланы бишектән өйрәт.
- Баланы караватта аркылы ятканда тыңлата алмасаң, буй яткач тыңлатырмын димә.
- Баланы тәрбия – үзеңне тәрбия.
- Балаңнан кадер күрергә өмет итсәң, тәрбиясен җиткереп ит!
- Баланың үскән бишеге киң дөньяның ишеге.
- Тал чагында бөкмәсәң, таяк булгач бөгә алмассың.
- Баланы яшьтән тый.
- Баланы яшьтән эшкә бөк!
- Баланы яшьтән өйрәт, хатынны баштан өйрәт.
- Баланы табуына караганда, тәрбияләү кыен.
- Баланы кыйнап юатма, көйләп юат.
- Улың яшьтә тәрбияче бул, улың үскәч, туган бул.
- Бала чагында алынган тәрбия чәч агарганчы үзе илә бергә булыр.
- Бала чагында алынмаган тәрбияне соңыннан бөтен дөнья халкы да өйрәтә алмас.

Димәк, никадәр иртәрәк без баланы үз-үзеңне тоту кагыйдәләренә өйрәтә башласак, шулкадәр җиңелрәк ул аларны кабул итәр.

Һәр ата-ана баласының яхшы кеше булып үсүен тели. Тәрбия – ата-аналарның, тәрбиячеләрең зур осталыгын, тырышлыгын һәм түземлеген таләп итә торган дәвамлы эш ул. Ә без, өлкәннәр, бала өчен, һәрнәрсәдә үрнәк булырга тиешбез.